# АЧЫК ТЫҢЛАУЛАР НӘТИҖӘЛӘРЕ

2019 елның 11 феврале — Кугәй авылы

Кугәй авыл җирлеге башлыгының 2019 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән Кугәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Кугәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләнде. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка игълан ителде .http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында( http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы Кугәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнашкан: Кугәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (авыл җирлеге администрациясе бинасында), Кугәй авылы, Үзәк урамы, 32 йорт (мәдәният йорты бинасында).

Ачык тыңлаулар 2019 елның 11 февралендә түбәндәге адрес буенча үткәрелде: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Кугәй авылы, Үзәк урамы, 32 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).

Ачык тыңлауларга чыгарылган мәсьәлә-карар проекты "Муниципаль берәмлекне төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында" Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Кугәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы.

Ачык тыңлауларны үткәрү инициаторы- Зеленодольск муниципаль районы Кугәй авыл җирлеге башлыгы.

Халык тыңлауларын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны – 2019 елның 11 феврале,16.00 сәгатьтә, Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Кугәй авылы, Үзәк урамы, 32 нче йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).

Ачык тыңлаулар үткәргән оештыру комитеты:

1. Хисаметдинова Фәния Хәбибулла кызы-Зеленодольск муниципаль районы Кугәй авыл җирлеге башлыгы,
2. Зиннәтуллина Алинә Рәшит кызы-Зеленодольск муниципаль районы Кугәй авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре,
3. Гирфанова Фәния Хәбибулла кызы-Кугәй авыл җирлеге депутаты, Олы Ачасыр авыл җирлеге башкарма комитетының исәп-хисап бүлеге начальнигы
4. Гыйләҗев Рамил Навил улы-Кугәй авыл җирлеге депутаты, «Красный Восток - Агро»механизаторы.

Ачык тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән чыгыш ясарга хокуклы катнашучылар турында мәгълүмат: докладчы, экспертлар, оештыру комитеты әгъзалары, Зеленодольск муниципаль районының Кугәй авыл җирлеге предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләре, Зеленодольск муниципаль районының Кугәй авыл җирлегендә яшәүчеләр.

Мәсьәләне хәл итү буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр булмады.

Җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты үзгәрешсез кабул ителде.

Ачык тыңлауларда катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре:

барлыгы 96 кеше.

Каршы 0 (кеше)

0 кеше тыелды.

Оештыру комитеты рәисе — Ф. Х. Хисаметдинова

Оештыру комитеты секретаре — А. Р. Зиннәтуллина